БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«_04_» ___11___ 2019 г. № _340_

2020 елга Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының балаларын йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү кыйммәте нормативларын раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балалар йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыруны финанслау нормативларын исәпләү буенча методик рекомендацияне раслау турында» 2010 ел, 5 июль, 545 нче карарының 3 нче пункты нигезендә Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Кушымталарны расларга:

- 2020 елга гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү кыйммәте нормативларын;

- Гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балалар йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү тәртибе турында Нигезләмәне.

2. Балтач муниципаль районының финанс-бюджет палатасына тәэмин итәргә:

- гомуми белем бирү оешмаларын әлеге карарның 1 нче пунктында расланган, балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү кыйммәте нормативлары нигезендә финанслауны.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникатив челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча игълан итәргә: http://baltasi.tatarstan.ru

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче А.Ф.Хәйретдинов

Татарстан Республикасы Балтач
район башкарма комитетының
2019 ел «_04_» __11__ _340_
номерлы
карары белән расланган

2020 елга Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының балаларын йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү кыйммәте нормативлары

| Автотранспорт чарасы моделе исеме | Ике ставкалы норматив күләме | |
|---|---|---|
| | бер автотранспорт чарасына ставка, 1 елга сумнарда | автотранспорт чарасы узуның бер километрына ставка, сумнарда |
| КАВЗ | 116398 | 37,42 |
| ПАЗ | 116656 | 37,35 |
| ГАЗ «Газель» | 110767 | 30,41 |
| УАЗ | 110314 | 29,04 |
| FIAT | 110057 | 27,47 |
| Peugeot Boxer | 110572 | 27,11 |
| Ford Transit | 110829 | 30,37 |
| Камаз Марко-Поло3297 | 119128 | 35,31 |

Татарстан Республикасы Балтач
район башкарма комитетының
2019 ел «_04_» __11__ _340_
номерлы
карары белән расланган

Гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балалар йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү тәртибе турында Нигезләмә

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү (алга таба - муниципаль хезмәт) бәясен исәпләү механизмын билгели.

1.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативы, автотранспорт чаралары саны һәм хисап чорында автотранспорт чараларының факттагы узышы (пробегы) нигезендә исәпләнә.

1.3. Балтач район башкарма комитеты ел саен муниципаль хезмәтләр күрсәтү бәясе нормативларын раслый.

1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен формалаштырганда автотранспорт чараларының факттагы узышы (пробегы) турындагы мәгълүмат автотранспорт чарасының расланган паспорты кысаларында эшләнгән автотранспорт чарасының хисап елындагы факттагы узышы (пробегы) буларак Татарстан Республикасында автотранспорт чараларының аерым төрләрен мониторинглауның бердәм системасы мәгълүматлары буенча кабул ителә.

2. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү

2.1. I муниципаль берәмлегенә муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$S_i = \sum_{m=1}^{k} (n_{f\,m} \times NF_{km_m} + NF_{as\,m} \times M_m),$$

биредә:

$S_i$ – муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе;

$n_{f\,m}$ - $m$ модельле автотранспорт чараларының факттагы узышы (пробегы), километр;

$NF_{km_m}$ - гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру нормативының ставкасы, бер километрга, сум;

$NF_{as\,m}$ - гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән бер автотранспорт чарасына йөртүне оештыру бәясе нормативының ставкасы, сум;

$M_m$ - $m$ модельле автотранспорт чаралары саны, берәмлек;

$m$ - муниципаль берәмлектә кулланыла торган автобус моделе номеры;

$k$ - муниципаль берәмлектә кулланыла торган автобус модельләре саны.